Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

КАРАР №5-2

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 19 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының «Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә җирләү урыннарын Күмү һәм карап тоту кагыйдәләре турында» 2011 елның 14 декабрендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 30.04.20021 ел, №119-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Уставының 32 статьясындагы 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2011 елның 14 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә җирләү урыннарын карап тоту һәм күмү кагыйдәләренә, түбәндәге эчтәлекле 1.4 пунктны өстәп, үзгәрешләр кертү:

"Ватанны саклаганда һәлак булганнарның каберлекләре бары тик Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары карары буенча гына «Ватанны саклаганда һәлак булучыларның истәлеген мәңгеләштерү турында»1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә генә күчерелергә мөмкин.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы, Ленин ур., 48А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р. Тажетдинов

СОВЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ